**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**Иске Тимошкино авыл җирлеге Башкарма комитеты.**

# КАРАР

**10.12.2019 ел.** **№ 8**

Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 24 декабрендәге 12 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Федераль мәгълүмат адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль законга үзгәрешләр кертү турында 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 24 декабрендәге 12 номерлы карары (№4 кушымта) белән расланган, адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
а) 1.5 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«адрес-Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структуралаштырылган һәм үз эченә шул исәптән урам-юл челтәре элементының һәм (яки) планлаштыру структурасы элементының атамасы (кирәк булганда), шулай ук адресация объектының санлы һәм (яки) хәреф-цифрлы билгеләнешен ала торган адресация объектының урнашу урыны тасвирламасы»;
б) 1.5 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«адресация объекты-капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект».

2. Әлеге карарны Иске Тимошкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Тимошкино авыл җирлеге башлыгы: Ф.Н.Степанов